**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**2022 елда Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премияләрен бирү турында**

Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясен бирү комитеты тәкъдимнәрен караганнан соң **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премияләрен түбәндәгеләргә бирергә:

1) Тимирясова Асия Виталий кызына – «В.Г. Тимирясов исемендәге Казан инновация университеты (Икътисад, идарә һәм хокук институты)» югары белем бирү хосусый мәгариф учреждениесе ректорына;

2) Туманов Дмитрий Александровичка – Татарстан Республикасының «Созвездие-Йолдызлык» төбәк яшьләр иҗтимагый оешмасы генераль директорына;

3) Шекуров Руслан Петровичка – «Донор-Сёрч» донорлыкны үстерү коммерциячел булмаган партнёрлыгы ассоциациясе директорына;

4) «Россия студентлар отрядлары» бөтенроссия яшьләр иҗтимагый оешмасының Татарстан төбәк бүлекчәсенә;

5) Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Әфганстандагы һәм Төньяк Кавказдагы сугыш хәрәкәтләре ветераннарының җирле иҗтимагый оешмасына;

6) «Татарстан Республикасы балалар оешмалары советы» төбәк иҗтимагый оешмасына;

7) «АЛЬПАРИ» хәйрия фондына;

8) «Татарстан энҗесе» инвалидларга ярдәм итү төбәк иҗтимагый оешмасына.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АДМИНИСТРАЦИЯ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2022 ел, 02 ноябрь
№ ПУ-782